ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УТАР-АТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Кооперативная, д. 22, с. Утар-Аты,
Арский муниципальный район, 422017

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УТАР-АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Кооператив урамы, 22 йорт, Утар-Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422017

Тел. (84366)50-3-31, факс (84366)50-4-22. E-mail: Utat.Ars@tatar.ru

# КАРАР

10 декабрь 2024 ел № 22

**Арча муниципаль районы "Утар-Аты авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Утар-Аты авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге уставы, "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясенең бер өлешендә) гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2022 елның 04 августындагы 61 номерлы Утар-Аты авыл җирлеге Советы карары нигезендә, 19.11. 2024 N7, 19.11. 2024 N8, 20.11. 2024 N9, 20.11. 2024 N10, 21.11. 2024г. N 11, 21.11. 2024 N 12 җыеннарда кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатыннан, Утар-Аты авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча муниципаль районы "Утар-Аты авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: ТР,Арча районы,Кушлавыч авылы, Тукай урамы,63 йорт,ТР, Арча районы, Субаш-Аты авылы, 9 Май урамы, 11 йорт; ТР, Арча районы, Югары Аты авылы, Кооператив урамы, 22 йорты; ТР, Арча районы, Утар-Аты авылы, Кооператив урамы, 22 йорт; ТР, Арча районы, Орнашбаш авылы, Яшьләр урамы, 6 йорт; ТР, Арча районы, Иске Җөлби авылы, Үзәк урамы, 7 йорты
3. "Утар-Аты авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында" 2023 елның 14 декабрендәге 29 номерлы Утар-Аты авыл җирлеге башкарма комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны өстемә алам.

Утар-Аты авыл
җирлеге башлыгы А.Г.Мөхәмәтгалиева

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ УТАР АТЫНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1609012653

Утар-Аты авыл җирлеге
башкарма комитетының
10 декабрь 2024 ел, № 22
карарына кушымта

**Арча муниципаль районы "Утар-Аты авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге тәртип Арча муниципаль районы "Утар-Аты авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә гражданнардан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын Арча муниципаль районы "Утар-Аты авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар, җыеннарда катнашуларына һәм тавыш биргәндә нинди мөнәсәбәттә булуларына карамастан, 2024 елның 21 февраленә кадәр түлиләр.

3. Гражданнарның түбәндәге категорияләре үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:

а) махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары (бергә яшәүче ата-аналар, ир яки хатын, балигъ булган балалар).

4. Гражданнарның аерым категорияләре өчен:

а) көндезге бүлектә белем алучы студентлар,

б) 1 төркем инвалидлар,

в) 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнар өчен түләү күләме җирле җыеннар карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итә.

5. Нигезле сәбәпләр булганда:

а) гаилә әгъзасының (ата-анасының, иренең/хатынының, балаларының) вафат булуы,

б) янгын яисә башка табигый бәла-казалар аркасында зыян килү гражданнарга гариза нигезендә түләү кертүне өч айдан да артмаган вакытка кичектерү бирелә.

6. Бер тапкыр түләнә торган түләү турында гражданнарга хәбәр итү бланкы (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгару, Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында урнаштыру, шулай ук кул куеп тапшыру яки почта элемтәсе аша җибәрү юлы белән җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр түләүнең тулы яисә киметелгән күләме, аны түләү срогы булырга тиеш.

7. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Арча муниципаль районы "Утар-Аты авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең шәхси счетына керә.

8. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясарга, почта күчерүләрен башкарырга хокуклы оешмалар (исәп-хисап оешмалары) аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча акча күчерү юлы белән башкарыла.

9. Түләү фактын приход касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслый торган башка документлар раслый.

10. Гражданнарның үзара салым акчалары билгеләнгән вакытта кертелмәгәндә, алар законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Утар-Аты авыл җирлеге
башкарма комитетының
10 декабрь 2024 ел, № 22
карарына 2 нче кушымта

**Утар-Аты авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә N _______________**

Түләүченең Ф.И.А.и___________________________________________________

Адресы:_______________________________________________________________

Нигезе_________________________________________________________

Сезгә ________________________ чараларны гамәлгә ашыруга бер тапкыр түләү____________________________________ суммада _____________ сум түләргә кирәк.

түбәндәге реквизитлар буенча:____________________________________________

алучының банкы БИК ____________________________

Сч. N _______________________________________

Алучы Сч. N ______________________________

ИНН ____________________________________________

КПП ____________________________________________

КБК _________________ОКАТО __________________

Түләүнең билгеләнеше
____________________________________________________________

Җитәкче _________________ ________________________________________

М. у. (имза) (имзаның аңлатмасы)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - кисем сызыгы - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

"Утар-Аты авыл җирлеге"муниципаль берәмлегендә бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләүне түләү турында хәбәрнамә №__
суммада _________________ сум

Түләүченең Ф. и.а.и. ____________________________________________________

Адресы: ________________________________________________________________

Алдым "___" _______________ 20__ ел ____________________________________

(түләүченең имзасы /ФИАи)

Искәрмә: хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, өзек тамыр тутырыла һәм Утар-Аты авыл җирлеге Башкарма комитетында кала